КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 сентябрь г.Казань № 828

2022/2023 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022/2023 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укыту буенча төп һөнәри белем бирү программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021/2022 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен раслау турында» 2020 ел, 3 сентябрь, 778 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 6 сентябрь, 828 нче
карары белән расланды

2022/2023 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укыту буенча төп һөнәри белем бирү программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга
норматив чыгымнар

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше исеме (белгечлек) | Белем алу вакыты, ай | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәрне һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, бер кешегә сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| 13.01.10 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер (тармаклар буенча) | 5 | 10 001 | 11 189 |
| 43.01.09 | Пешекче, кондитер | 4 | 7 333 | 8 126 |
| 29.01.08 | Тегү җиһазлары операторы | 3 | 6 174 | 6 866 |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 5 | 10 858 | 12 227 |

___